РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«16» декабрь, 2015 ел Олы Кайбыч ав. № 18

2016 елга Кайбыч муниципаль районы бюджеты турында

РФ Бюджет кодексы, ТР Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставының 16, 78, 79 ст. нигезендә Кайбыч муниципаль районы Советы карар кылды:

1 статья

1. 1. 2016 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетының фаразланыла торган керемен 316268,37 мең сум күләмендә;

2) Кайбыч муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 316268,37 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты кытлыгы 0,00 мең сум.

2. 2016 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. 2016 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 статья

1. 2017 елның 1 гыйнварына Кайбыч муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә билгеләргә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча - 0 мең сум.

2. 2016 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль бурычының иң чик күләмен 0 мең сум күләмендә билгеләргә.

3 статья

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетында 2016 елга фаразланучы керем күләмен әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60.1 статьясындагы 2 пункты һәм муниципаль район Уставының 79 статьясындагы 9 пункты нигезендә 2016 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.

5 статья

2016 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре табышының 2015 ел йомгаклары буенча салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләр керткәннән соң кала торган өлеше 2016 елның 1 июленә кадәр чиста табышның 30 проценты күләмендә күчерелә дип билгеләргә.

6 статья

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

7 статья

1. 2016 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.
2. 2016 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре буенча әлеге карарның 7 нче кушымтасы нигезендә бюджет ассигнованиеләрен бүлүне расларга (алга таба - Кайбыч муниципаль районы бюджеты бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (дәүләт һәм муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре).
3. 2016 елга бюджет чыгымнарының максатчан статьялары (дәүләт һәм муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен әлеге законга 8 нче кушымта нигезендә бүлүне расларга.
4. 2016 елга ачык норматив йөкләмәләрне үтәү өчен Кайбыч муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 1040,00 мең

сум күләмендә расларга.

8 статья

Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә һәм физик затларга - товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә субсидияләр Кайбыч муниципаль районы Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә бирелә.

9 статья

1. «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 07.12.2011 ел, № 6-ФЗ Федераль законны үтәү йөзеннән, әлеге карарның 9 нчы кушымтасы нигезендә, 2016 елда төзелгән килешүләр нигезендә, тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетында җирлекләр бюджетларыннан Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен расларга.

2. Тиешле җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына җирлекләр бюджетларында әлеге статьяда күрсәтелгән бюджетара трансфертларны күздә тотарга.

3. Тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча бюджетара трансфертлар Кайбыч муниципаль районы бюджетына 1 апрельгә кадәр ике өлеш белән бюджетара трансфертларның еллык күләменең кимендә 1/2 өлеше күләмендә һәм 1 октябрьгә кадәр бюджетара трансфертларның калган өлеше күчерелә.

10 статья

2016 елга җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен әлеге карарның 10 нчы кушымтасы нигезендә 18092,10 мең сум күләмендә расларга.

11 статья

2016 елга җирлекләр бюджетларының баланслылыгын тәэмин итү чараларына ярдәм итү өчен җирлекләр бюджетларына 214,30 мең сум күләмендә дотацияләр күләмен расларга 11 нче кушымта нигезендә әлеге карарга 11 нче кушымта нигезендә бүленеп.

12 статья

12 нче кушымта нигезендә бүленеп, 2016 елга гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлек бюджетларына субвенция күләмен 3,5 мең сум күләмендә расларга.

13 статья

2016 елга хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларына субвенция күләмен әлеге карарга 13 нче кушымта нигезендә бүленеп, 1360,2 мең сум күләмендә расларга.

14 статья

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетында 2016 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны исәпкә алып, бюджетара трансфертларны әлеге карарның 14 нче кушымтасы нигезендә, 221153,87 мең сум күләмендә исәпкә алырга.

15 статья

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен 7916,6 мең сум күләмендә расларга һәм аларны 2016 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлтергә.

16 статья

2016 елда Кайбыч муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына бюджет кредитлары бирелмәвен билгеләргә.

17 статья

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнары 2016 елда муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм башка оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга, шулай ук аларны карап тотуга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2016 елда муниципаль хезмәткәрләр, учреждениеләр һәм бюджет өлкәсенең башка оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә киңәш итәргә.

18 статья

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетын үтәгәндә әлеге карар белән расланган керемнәрнең гомуми күләменнән чыгып фактта алынган керемнәр, әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә, муниципаль бурычны түләүгә, суд актларын үтәүгә, районда яшәүче һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ аз керемле гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итүгә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 217 статьясындагы 3 пунктында

каралган күләмдә аларны үтәү өчен билгеләнгән күләмдә гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетын үтәгәндә әлеге карар белән расланган керемнәрдән тыш фактта алынган субсидияләр һәм субвенцияләр, әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертмичә, субсидияләр һәм субвенцияләр бирү максатларында чыгымнарны арттыруга юнәлдерелә.

Статья 19

Кайбыч муниципаль районы бюджеты акчалары Кайбыч муниципаль районы исеменнән төзелгән товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүгә муниципаль контрактлар нигезендә 2015 елда түләнергә тиешле муниципаль контрактлар өчен кулланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә Кайбыч муниципаль районы башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, 2016 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә.

20 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә бюджетның касса үтәлеше буенча аерым функцияләрне һәм Кайбыч муниципаль районы бюджеты үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

21 статья

Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

22 статья

Әлеге карарны «Кайбыч таңнары» газетасы битләрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

**Совет Рәисе,**
**Кайбыч муниципаль**
**районы Башлыгы** **А.И.Рәхмәтуллин**